ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОЛЯНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422643, д. Полянка,
ул. Механизаторов, дом 3б

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ПОЛЯНКА
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422643, Полянка авылы,
Механизаторлар урамы, 3б нче йорт

Тел.: (84361) 24002, , Pol.Rs@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 елның 7 май Полянка авылы № 8

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Полянка авылҗирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеген игезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм "Җирләү һәм мәет куюэше турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсендәге 3 пунктын, 12 маддәсендәге 3 пунктын үтәү йөзеннән,Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында" 2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карарына,"Татарстан Республикасында "Җирләү һәм мәет куюэше турында" Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында" 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 3 пунктына таянып КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Полянка авыл җирлегендә мәет кую буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1,2 кушымталар нигезендә 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм 2019 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә,

2.Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Полянка авылы, Механизаторлар урамы, 3б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Полянка авыл җирлеге башлыгы Х.Ф. Хашимов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Полянка авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның 7 маендагы
8 номерлы карарына
кушымта №1

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районының Полянка авыл җирлегендә**
**2019 елның 1 февраленнән мәет куюбуенча хезмәтләрнең**
**гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган**
**хезмәтләрнең бәясе**

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләүөченкирәкледокументларнырәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табут һәм җирләүөченкирәклебашка әйберләрне бирүһәмкитерү | 1697 |
| 3. Мәрхүмнеңҗәсәден (мәетен) зиратка (крематорийга)күчерү(илтү) | 929 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру, соңыннан көле салынган урнаны бирү белән) | 3320,47 |
| Барлыгы: | 5946,47 |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы  Полянка авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 елның  7 маендагы
8  номерлы карарына
кушымта  №2

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлегендә ире (хатыны), якын туганнары, башка туганнары яисә мәрхүмнең законлы вәкиле булмаганда яки алар тарафыннан җирләүне гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда яисә җирләү бурычын үз өстенә ала торган бүтән зат булмаганда, мәет кую буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча түләүсез нигездә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе**

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләүөченкирәкледокументларнырәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 468 |
| 3.Табутһәмҗирләүөченкирәкле башка әйберләрнебирүһәмкитерү | 1229 |
| 4.Мәрхүмнеңҗәсәден (мәетен) зиратка алып бару (илтү) | 929 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3320,47 |
| Барлыгы | 5946,47 |